**ГЛАВА**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «15» апреленнән № 12

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 17 гыйнварындагы 1 карарына үзгәрешләр кертү хакында

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 апрелендәге 17 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирәм:

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 17 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарының кушымтасын түбәндәге редакциядәге кушымтада каралганча бәян итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:// pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә

муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгының
2022 елның «15» апрелендәге
12 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемле

| ТР КоАП статьялары | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|
| Статья 2.4.<br>Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр | - Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе |
| 2.5 нчы статья<br>Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү | - Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе<br>Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының кадрлар секторы мөдире |
| 2.6 нчы статья<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларының (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының норматив – хокукый актлары) үтәлмәве | - Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе |
| 2.7 нчы статья<br>Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу | - Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе |